Үзәкләштерелгән дини оешма

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

بسم الله الرحمن الرحيم

# ГЫЙД ӘЛ-ФИТР (УРАЗА ГАЕТЕ) УҢАЕННАН

## Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе Баш мөфти шәех Равил Гайнетдин мөрәҗәгате

1 шәүвәл 1446 һиҗри ел
(2025 елның 30 марты)
Мәскәү

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**Мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе булган Аллаһ исеме белән!**

Рәхмәте киң булган галәмнәрнең Хуҗасы, күк белән җирне бар кылучы, бар мәхлукат тарафыннан данланучы һәм һәрнәрсәгә рәхимле Аллаһка мактау булсын! Пәйгамбәрләрнең һәм расүлләрнең соңгысы Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

**Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек,**

**Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм!**

**Кадерле дин кардәшләрем!**

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән сезне, туганнарыгызны һәм якыннарыгызны ике зур бәйрәмебезнең берсе — һиҗри 1446 елның Ураза бәйрәме — Гыйд әл-Фитр белән котлыйм.

Уразаларыбыз, догаларыбыз, игелекле гамәлләребез һәм биргән садакаларыбыз Аллаһы Тәгалә тарафыннан кабул булсын! Аларның әҗерен галәмнәрнең Раббысы бу дөньяда да, мәңгелектә дә насыйп итсен!

Аллаһы Тәгалә болай дигән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

**«И иман китергән кешеләр! Сезгә, сездән алдагы кешеләргә фарыз ителгән кебек, ураза фарыз ителде. Шулвакыт сез Аллаһтан куркучы булырсыз»**
(«Әл-Бәкара» сүрәсе, 183 нче аять).

Аллаһ Үзенең колларына, аларга карата күрсәткән мәрхәмәтен мәҗбүри ураза тотарга кушып белгертте. Бу боерык аннан алдагы дини җәмгыятьләргә дә иңдерелгән булган, чөнки кайсы гына заманда булмасын, ураза кешеләргә һәрвакыт файда китерә торган гамәлләр исәбенә керә. Аллаһ мөселманнарны игелекле гамәлләр кылырга һәм күркәм сыйфатларга ирешергә өнди. Аллаһы Тәгалә диндарлык һәм тәкъвалыкка ирешергә ярдәм итүче уразаның файдасы турында хәбәр итә, чөнки ураза тотучы мөселман Раббысының әмерен үти һәм тыелган гамәлләрдән ерак тора.

Ураза тотучы үзен
һәрвакыт Аллаһы Тәгалә
күзәтүе астында булуын истә
тотарга өйрәтә. Ул аңлы рәвештә
күз алдында гына ымсындырып торган
ләззәтләрдән баш тарта һәм моны ул Раббысы
күзәтүен белеп эшли.

Әбү Һөрәйра радыйаллаһу ганһү сүзләреннән,
Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең
еш кына болай диюе билгеле:

الصَّلَوَاتُ الخَمْسُ، وَالجُمُعَةُ إِلَى الجُمُعَةِ، وَرَمَضَانُ إِلَى
رَمَضَانَ مُكَفِّرَاتٌ لِمَا بَيْنَهُنَّ إِذَا اجْتُنِبَتِ الكَبَائِرُ

*«Көндәлек биш вакыт намаз уку, алдагысыннан соң киләчәк һәр җомга намазында катнашу һәм алдагысыннан соң һәр киләчәк Рамазанда ураза тоту, алар арасында кылынган гөнаһлардан арындыра, әгәр ки, ул гөнаһлар арасында зур гөнаһлар булмаса»* (Әхмәд).

Аллаһы Тәгалә болай дигән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ
لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм җан иртәгәгә нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһтан куркыгыз, Аллаһ нәрсә кылганыгыздан хәбәрдар бит»**
(«әл-Хәшр» сүрәсе, 18 нче аять).

Аллаһ Үзенең мөэмин бәндәләренә диннәре кушканча яшәргә, ягъни ялгызы гына калганда да, халык алдында да, һәр мизгелдә һәм һәркайда Аллаһыдан куркырга; Аның әмерләрен үтәргә һәм Ул куйган чикләрне бозмаска; үзенә файда һәм киресенчә, зыян китерә торган нәрсәләр турында уйланырга; шулай ук Кыямәт көнендә хисап алыначак яхшы һәм начар гамәлләр турында уйланырга куша. Кешеләр карашларын һәм күңелләрен Ахирәткә юнәлтсә һәм андагы үз урыны турында уйланса, хак ки, игелекле гамәлләрне тырышыбрак кылачак. Әгәр алар кылган эшләреннән Аллаһның хәбәрдар икәнлеген һәм югалмаячагын яки онытылмаячагын истә тотса, әлбәттә, бар көчләрен изге гамәлләр кылуга сарыф итәр. Изге Коръән безне үз гамәлләребезгә бәя бирергә һәм үзебезгә карата таләпчән булырга өйрәтә. Ул хаталарыбызны аңларга, аларны кабатламаска, тәүбә кылырга, шулай ук гөнаһлардан һәм Раббыбызга каршы барудан тыелырга өйрәтә. Ул безне һәр нәрсәгә Кодрәтле Раббыбыздан ярдәм сорап, төзәтеп һәм тырышлык куеп, җитешсезлекләребез турында уйланырга мәҗбүр итә.

Аллаһның илчесе саллəллаһу галəйһи вə сəлləм болай дигəн:

اتّقِ اللّهَ حَيْثُمَا كُنْتَ وأَتْبِعِ السَّيِّئَةَ
الْحسنةَ تَمْحُهَا، وخَالِقِ النَّاسَ بخُلُقٍ حَسَنٍ

*«Кайда гына булсаң да, Аллаһтан курык, начар гамəлдəн соң начарлыкны сөртəчəк яхшылык кыл! Кешелəр белəн мөнəсəбəттə дə əхлаклы бул»* (Əхмəд).

Рамазан ае — Аллаһ кушканнарны тырышып үтəү һəм Ул тыйганнардан аеруча читлəшү вакыты. Аллаһның рəхмəте белəн, бу Рамазан ае ураза тотуда, Коръəнне өйрəнүдə, хəйрия эшлəрен башкаруда ихлас тырышкан кардəшлəребезнең күп игелекле гамəллəре белəн сугарылып узды. Аллаһка шөкер, без ел саен оештырыла торган Рамазан-Кəрим акциясен уздырдык, аның барышында аз керемле кешелəргə, ярлыларга, өлкəннəргə, балалар йортларына һəм приютларга, махсус хəрби операциядə катнашып, яраланган Ватан сакчылары дəваланучы госпитальлəргə һəм хастаханəлəргə, барлыгы дистəлəрчə мең азык-төлек җыелмасы тапшырылды. Без фронтның алгы сызыгына, хəрби частьларга һəм ирекле отрядларга гуманитар ярдəм җибəрдек. Болар барысы да Аллаһының рəхмəте һəм хəйриячебез Сөлəйман Əбүсəид улы Кəримовның юмартлыгы сəбəпле булды, аңа Аллаһы Тəгалə муллык, юмартлык һəм күркəм холык, хəйрия эшлəре аша Раббыбыз юлында риясыз хезмəт итү мөмкинлеген биргəн. Шулай ук «Хаҗ Кəрим-2025» хəйрия акциясе нигезендə хаҗга документлар кабул итү тəгаллəнде. Без 25 мең ватандашыбыз, шул исəптəн Сөлəйман Кəримов фида кылган хəйрия юлламалары буенча хаҗ кылачак 5000 кардəшебез, хаҗның бар йолаларын тырышып үти алсын һəм өйлəренə исəн-имин кайтсын дип догада калабыз.

Аллаһы Тəгалə кешегə исəпсез-хисапсыз мəрхəмəт күрсəтте һəм нинди гамəллəрнең яхшылык белəн бəхеткə алып барганлыгын аңлатты. Ул яхшылык эшлəргə ашыгырга һəм начарлык кылмаска кушты. Ул һəр кешегə бар кешелек дөньясын бəхетле итəргə омтылуын, кешелəргə аларның үзара мөнəсəбəте ярату, ышаныч, хөрмəт, кызгану һəм бер-берсенə ярдəм итүгə нигезлəнүен боерды. Безнең һəркайсыбыз икенче берəвебезгə ярдəм кулын сузарга əзер булсын, нияте игелектə булсын, мəрхəмəтле һəм дус булуы белəн аерылып торсын, яхшы сүзлəр генə сөйлəсен. Шушылар нəтиҗəсендə кеше уңышка, ə тулаем алганда, бар кеше ике дөньяда да бəхеткə ирешə алачак.

Кардəшлəремне бу бөек Рамазан сынавының тəмамлануы һəм иманыбызның ныгуы, һəм Гыйд əл-Фитр — пакьлəнү бəйрəме белəн ихластан котлыйм! Без барыбыз да галəмнəрнең Хуҗасыннан дөньяга тынычлык, хакыйкатьнең наданлык белəн гаделсезлектəн өстен чыгуын, гаилəлəребезгə һəм Ватаныбызга иминлек сорыйбыз. Һəм Аллаһы Тəгалə безнең догаларыбызны, гыйбадəтлəребезне, тоткан уразаларыбызны, фида кылган малларыбызны кабул итсен, йөрəклəребезгə тынычлык, гаилəлəребезгə һəм йортларыбызга иминлек һəм бəхет-сəгадəт бүлəк итсен! Əмиин!

والسلام عليكم ورحمة الله وبركاته

*Ихтирам белəн сезнең өчен кардəшлек догасында калып,*
***Баш мөфти шəех Равил Гайнетдин,***
***Россия Федерациясе мөселманнары диния нəзарəте рəисе***